«Болгар санатория интернат – мәктәп”
белем бирү учреждениесе

# Татар халкының каһарманы – Муса Җәлил

**Проектны эшләделәр:**
9 нчы сыйныф укучылары
Шарафуллина Гүзәл һәм Яппаров Фирүз

“Батыр үлә үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып,
Исмең калсын үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.”

М.Җәлил



# Татар халкының каһарманы – Муса Җәлил

**Батыр** – курыкмаучанлык, кыюлык, көчлелек, уңганлык сыйфатлары белән танылган шәхес.


# Сугыш еллары




1941 елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М. Җәлил Мәскәү аша фронтка китә.



1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы  сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган  хәлендә дошман кулына эләгә.



# 791 көн әсирлектә





Төрмәнең караңгы, тар, таш бүлмәсендә бөтен Җир шарын йөрәгенә
сыйдырган  нечкә күңелле, кешелекле шагыйрь яши.
Үзенең үләсен белеп, дөньяның олылыгын
тоеп, киләчәкнең үзе көткәнчә булачагына омтылып яши. Яши
генә түгел, көрәшә:  шигъри сүзе белән, фәлсәфәсе,
мәхәббәте белән...
Ватанга мәхәббәт һәм сөйгәненә мәхәббәт аның йөрәгендә
бергә яши:



Илдән киттем ил һәм синең өчен,
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алыштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?!
Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
“Муса инде үлгән”, - дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

“Моабит дәфтәрләре” – Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Сугышка кадәрге иҗатында ирешелгән казанышлар биредә тагын да үстерелде, баетылды. Шагыйрьнең сугыш эчендә кеше, солдат һәм әдип буларак олы сынау үтте, зур фаҗига кичерүе, искиткеч шартларада рухи көрәш алып  баруы аның сәнгатьчә осталыгын да үткенәйтте, шигъри хисләрне дә яңа биеклеккә күтәрде.






Җәлил шигырьләре халкыбызның рухи дөньясына яңа байлыклар өстәде, әдәбиятыбыз мирасына кыйммәтле хәзинә булып керде һәм шагыйрьгә үлемсезлек алып килде. Татар әдәбиятына шундый олы байлык биргән шагыйрь 1957 елда Ленин премиясе белән бүләкләнде.



**Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре буенча СССР Министрлар Советы янындагы комитетта Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә аеруча күренекле казанышлар өчен Ленин премияләре бирү турында**

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитеты аеруча күренекле әдәбият, музыка, сынлы сәнгать әсәрләре өчен һәм театр сәнгате эшлеклеләренең аеруча күренекле казанышлары өчен 1957 елгы Ленин премияләре бирергә карар бирде:

1. Сергей Тимофеевич Коненковка — «Автопортрет» скульптурасы өчен.
2. Леонид Максимович Леоновка — «Рус урманы» романы өчен.
3. Муса Җәлилгә — «Моабит дәфтәре» исемле шигырьләр циклы өчен.
4. Сергей Сергеевич Прокофьевка — Җиденче симфония өчен.
5. Галина Сергеевна Улановага — балет сәнгатендәге күренекле казанышлары өчен.





Үзенең халыкчан иҗаты, үлемсез шигырьләре белән Муса Җәлил халкыбызның рухи тормышында бүген дә актив катнаша. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне,
"Үлем" диеп әйтеп буламы соң,
Җиңеп үлгән мондый үлемне?
("Ышанма", 1943).

Бүгенге көрәштә Муса Җәлил дә үзенең шигырьләре белән бер сафта атлый.

Ул якты һәм матур тойгылар тәрбияли, кешеләрдәге һәм тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.

